# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Яңасала авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**14 ноябрь 2024 ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 14 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Яңасала авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңасала авылында юл-урам челтәренә вак таштан нигез салу һәм аны каплау, Мәктәп урамының 1 нчы йортыннан 6 нче йортка кадәр, Яшьләр урамының 19 нчы йортыннан 21 нче йортка кадәр).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 194 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 103 граждан кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 99 кеше тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Арча муниципаль район Яңасала авыл җирлеге Яңасла авылында халык җыены узды, җыен нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Яңасала авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа

инвалидлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңасала авылында юл-урам челтәренә вак таштан нигез салу һәм аны каплау, Мәктәп урамының 1 нчы йортыннан 6 нче йортка кадәр, Яшьләр урамының 19 нчы йортыннан 21 нче йортка кадәр).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга»

соравы буенча карар кабул ителде дип санарга.

3. Әлеге карарны гражданнар күпләп җыела торган урыннарда: ТР, Арча районы, Яңасала авылы, Үзәк урам, 18 йорт адресы буенча мәгълүмат стендында, Арча муниципаль районның (http://arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеше башлыгы А.И.Сафин